ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
22 нче гыйнвар, 2025 ел

**РЕШЕНИЕ**
№44-05

## 2025, 2026 елларда Актаныш муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 26 декабрендәге 494-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2025, 2026 елларда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары белән Актаныш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында һәм муниципаль органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелмәскә мөмкин дип билгеләргә.
2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләгәндә әлеге карарның 1 пункты кулланылмый.
3. Әлеге карарны «Актаныш таңнары» район газетасында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмати порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Актаныш муниципаль районы
Советы рәисе — Л.Р.Зарипов